ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН УРЫСБАГА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15 июль 2025 ел.**

Түбән Урысбага

**КАРАР**
**№ 8**

Түбән Урысбага авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 24 мартындагы 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында " Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Түбән Урысбага авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 24 мартындагы 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

«4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.»

2 1. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында .http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы,

Үзәк урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Түбән Урысбага
авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Сибгатуллин.